# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында

30 ноябрь 2019 ел № 4

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Песәй авыл җирлеге Песәй авылы халык җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2020 елда Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Тукай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшүсмердән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә, I һәм II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылар өчен бер тапкыр түләнә торган түләүне киметергә, тәрбиясендә балигъ булмаган балалары булган күп балалы гаиләләр, көндезге уку бүлегендәге студентлары, Россия Армиясе сафларына вакытлы хезмәткә чакырылган гражданнарга һәм әлеге категория гражданнар өчен 150 сум күләмендә билгеләргә кирәк.
2. Алынган үзара салым акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:
   1) Песәй авылында юлларны кардан чистарту
   2) Песәй авылында вак таш сатып алу
   3) Песәй авылында вак таш тигезләү
   4) Песәй авылында ясалма тигезсезлек, билгеләр урнаштыру
   5) генератор сатып алу
   6) Песәй авылы чишмәсен төзекләндерү
3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендына түбәндәге адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Песәй авылы, Үзәк ур. 4, һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru "Песәй авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Песәй авыл җирлеше башлыгы Мөхәммәтгалиев В.И.